РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.06.2026 Буа шәһәре №218/Бк/к

Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2026елның 26 февралендәге 56/Бк/к номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль бюджет мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле белем бирү хезмәтләренә тарифларны раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль закон (29.12.2025 елгы редакциядә), «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы (28.12.2025 елгы редакциядә), 27.05.1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы «Хәрби хезмәткәрләр статусы» Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 15 сентябрендәге 1441 номерлы «Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» карары, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы РФ Законы белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль бюджет мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле белем бирү хезмәтләренә ата-ана түләвен керткәндә ташламалар кагыла торган затлар исемлеге» 2 нче кушымтасын өстәп, Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2026елның 26 февралендәге 56/Бк/к номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль бюджет мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле белем бирү хезмәтләренә тарифларны раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат

порталында рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә (https://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш (http://buinsk.tatarstan.ru), һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Н.А.Македонскаяга йөкләргә.

Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р. Шакирҗанов

Карарга 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль бюджет мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле белем бирү хезмәтләренә ата-ана түләвен керткәндә ташламалар кагыла торган затлар исемлеге.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының муниципаль бюджет мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле белем бирү хезмәтләренә ата-ана түләве алынмый:

- инвалид балаларның, ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, шулай ук туберкулез интоксикациясе булган балаларның ата-аналарыннан;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләреннән (гаилә әгъзалары), Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәр һәм затлар, Татарстан Республикасында оештырылган "Алга", " Тимер " һәм " Батыр " батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре гаиләләреннән, шулай ук югарыда күрсәтелгән категория гражданнар гаиләләреннән (гаилә әгъзаларыннан), махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булганнар (вафат булганнар) (алга таба — гаиләләр) гаиләләреннән (гаилә әгъзаларыннан)

Муниципаль мәгариф оешмаларында түләүле белем бирү хезмәтләре өчен түләүгә ташлама ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы һәм гаиләнең ташламага хокуклы булуын раслый торган документлар нигезендә бирелә.